РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЛАШЧЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 сентябрь 2018 ел № 54-2

«Физик затларның милкенә салым турында»
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Югары Лашчы авыл җирлеге Советы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр хакыннан чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәй датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

I. ТР Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 1-56 номерлы карарына (2015 елның 21 маендагы 1-67 номерлы, 2015 елның 8 октябрендәге 2-1 номерлы, 2018 елның 20 июнендәге 47-1 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 2 пунктның 2, 3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 0,2 процент түбәндәгеләргә карата:

фатирларга;

фатирларның өлешләренә;

бүлмәләргә;

3) 0,3 процент түбәндәгеләргә карата:

торак йортларга;

торак йортларның өлешләренә;

төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына, әгәр әлеге объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса;

составына бер генә булса да торак йорт керсә, бердәм күчемсез комплексларга».

2. Түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар белән тулыландырырга:

«4. Физик затларның милкенә салым түләүдән азат итәргә:

4.1. 18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарны;

4.2. әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

5. Салым ташламасы салым салынучы түбәндәге төр объектларга карата тәкъдим ителә:

1) Фатир, фатирның өлешләре (бүлмә) яки торак йорт, торак йорт өлешләре.

Гаиләгә туры килгән салым салынучы бер объектка карата салым ташламасы салым түләүче сайлавы буенча билгеләнә. Салым түләүчеләргә салым ташламасы Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә даими яшәгән, салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмаган салым салынучы объектка карата, салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә тәкъдим ителә.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына салым ташламасы бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукны дәлилләүче документлар тәкъдим итә. Салым ташламасы бирелгән, сайланган салым салынган объектлар турындагы белдерү кәгазе салым түләүче тарафыннан салым органына салым периоды булган елның 1 ноябренә кадәр тәкъдим ителә, шул вакыттан күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла.».

3. 4, 5 һәм 6 пунктларны тәңгәл рәвештә 6, 7 һәм 8 пунктлар дип исәпләргә.

II. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

III. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Югары Лашчы авыл җирлеге
башлыгы Г.Х. Усманова